ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГАЙТАНКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ГӘЙТӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423014, РТ, Нурлатский район, с. Гайтанкино, ул. Садовая, дом 17
Тел. 8 (84345) 3-98-01

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06 май 2026 ел № 5

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлеге Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлеге муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче затның һәм Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлеге муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2013 елның 18 мартындагы 5 номерлы карары үз көчен югалткан дип тану хакында**

**«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлеге Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлеге муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче затның һәм Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлеге муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2013 елның 18 мартындагы 5 номерлы карары үз көчен югалткан дип таныргa.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында https://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында да http://nurlat.tatarstan.ru/, җирлек территориясендә мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе җаваплылыгында калдырырга.

Җитәкче Н.В. Авдеева